РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость, 423104**

**Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы, 423104**

**тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru**

№60 30.01.2023 ел

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Шешминка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендәге 93 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка

авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендәге 93 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына (Шешминка авыл җирлегенең 2020 елның 26 октябрендәге 8 номерлы, 2022 елның 18 ноябрендәге 56 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи окладының күләме 12688 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче кушымтада III бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында түбәндәгеләрне бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләк - вазыйфаи окладларының 18 процентыннан артмаган күләмдә»;

1.3. 7 нче кушымтаның 1 пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш айлык акчалата бүләк түләнә. Муниципаль хезмәткәрләрне айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә»;

1.4. «2 нче кушымта «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен» 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Шешминка авыл җирлеге

башлыгы, Советы рәисе М.Д.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советының
2023 елның 30 гыйнварындагы
60 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советының
2018 елның 23 апрелендәге
93 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Үз вәкаләтләрен авыл җирлегендә даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме**

| **Вазыйфалар атамасы** | **Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда)** |
|---|---|
| Башлык | 17390,00 |